**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлегенең Яңа Саклау торак пунктында
2025 елда үзара салым кертү турында

**15.11.2024 ел** **№ 4**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә« “Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Яңа Саклау авылында 2025 нче елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында” Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 05 ноябрендәге 6 номерлы карары нигезендә 2024 елның 15 ноябрендә 15.00 сәгатьтә узган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең Яңа Саклау авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1) «Саклаубаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, I төркем инвалидларыннан тыш, вакытлы хәрби хезмәт үтүчеләрдән тыш, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш һәрбер гражданнардан 1000 сум күләмендә 2025 елда үзара салым акчаларын кертергә һәм аны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1) Халыкның массакүләм ял итү урыннарын төзекләү (брусчатка җәю)

2) 2024 елда «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегендә Саклау-Баш авыл җирлегендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 17.11.2023 ел, №1 карары нигезендә Саклаубаш авыл җирлеге бюджетына кергән «1) традицион күмү урыннарын төзекләндерү (койма тоту) » гә билгеләнгән гражданнарның үзара салым акчасын төзелеш материалларына бәяләр үзгәрү сәбәпле түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә файдаланырга, шуңа бәйле рәвештә түбәндәге максатларга җибәрергә:

- 1) традицион күмү урыннарын төзекләндерү (зиратка перфоратор һәм генератор сатып алу)

3. Әлеге карарны Саклаубаш авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Л.М.Габидуллина